**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 43-10 «26» август 2021 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советының 2008 елның 25 декабрендәге 111-30 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджет процессы турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (23.07.2009 №140-37, 11.12. 2009 №148-40, 11.11.2010 №7-2, 20.04.2011 №27-7, 22.10.2013 №103-31, 12.08.2014 №135-40, 21.10.2015 №9-2, 09.11.2017 №67-19, 20.08.2019 №142-35, 22.10.2019 №147-36, 12.03.2020 №162-41, 16.06.2020 №174-43, 14.12.2020 №17-3 карарлар редакциясендә)

2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы
карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советының 2008 елның 25 декабрендәге 111-30 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджет процессы турында» Нигезләмәгә (23.07.2009 №140-37, 11.12. 2009 №148-40, 11.11.2010 №7-2, 20.04.2011 №27-7, 22.10.2013 №103-31, 12.08.2014 №135-40, 21.10.2015 №9-2, 09.11.2017 №67-19, 20.08.2019 №142-35, 22.10.2019 №147-36, 12.03.2020 №162-41, 16.06.2020 №174-43, 14.12.2020 №17-3 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 15 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Шәһәр бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

1) Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасының нигезләмәләре;

2) Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы;

3) шәһәрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

4) Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеше фаразы;

5) озак сроклы чорга шәһәрнең бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);

6)муниципаль программалар (муниципаль программалар проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары);

7) Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар.».

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин